*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 60 минут**
**Максималь балл – 38**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Калын сузык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [ы];
   ә) [э];
   б) [ә];
   в) [и].

2. Саңгырау тартык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [в];
   ә) [д];
   б) [з];
   в) [һ].

3. Антонимнардан торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *җылы – кайнар*;
   ә) *карт – яшь*;
   б) *шәһәр – кала*;
   в) *председатель – рәис*.

4. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *илле*;
   ә) *ундүрт*;
   б) *егерме өч*;
   в) *туксан*.

5. Төшем килешенең кушымчаларын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) -*ның/-нең;*
   ә) -*га/-гә, -ка/-кә*;
   б) -*ны/-не*;
   в) -*да/-дә, -та/-тә*.

6. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *яшел;*
   ә) *яшелрәк;*
   б) *ямь-яшел;*
   в) *яшькелт.*

7. Күрсәтү алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) *син;*
ә) *кем;*
б) *аларныкы;*
в) *теге.*

8. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Илгизнең энесе балалар бакчасына йөри.*

а) хикәя;
ә) сорау;
б) боеру;
в) тойгылы.

## II. Теоретик бирем.

Күпнокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(6 балл)**

*[с] –* **……………….** *тартык аваз. [у] –* **………………** *сузык аваз. Калын – юан –* **……………….** *. Алтынчы, сигезенче –* **……………….** *саннары. Укысын –* **……………….** *фигыль. Ия һәм хәбәр – җөмләнең* **……………….** *кисәкләре.*

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

*Как красив осенний лес! Березки надели золотые платья. Сосны и ели остались зелёными. Пестрый ковёр листьев шуршит под ногами. А сколько грибов в лесу!*

2. Көзге урман турында дәвам итеп, 6 җөмлә төзеп языгыз. **(6 балл)**